ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ УПРАВЛЕНИЯ ОБРАЗОВАНИЯ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОДА КАЗАНИ ПО СОВЕТСКОМУ РАЙОНУ

# ПРИКАЗ

№ 46 от 27.02.2023

**О проведении районного этапа городского конкурса «Сәләтле буын» («Талантливое поколение»)**

В целях реализации творческого потенциала учащихся, выявления и поддержки талантов, расширения круга интересов среди учащихся образовательных организаций Советского района г.Казани, содействия в удовлетворении ими духовных, интеллектуальных, творческих и социальных потребностей, во исполнение Муниципальной программы по укреплению гражданского согласия в г. Казани в 2014-2023г., реализации совместного проекта с детским телеканалом «Шаян-ТВ» и в рамках Года национальных культур и традиций

**ПРИКАЗЫВАЮ:**

1. Провести 14 марта 2023 года в заочной форме (просмотр видеороликов) в «Центре детского творчества пос. Дербышки» районный этап городского конкурса «Сәләтле буын» среди учащихся общеобразовательных школ.
2. Утвердить Положение о проведении районного конкурса (Приложение1).
3. Назначить ответственными за организацию и проведение конкурса Ф.М. Гумерову, директора ЦДТ пос. Дербышки, Л.М.Антонову, заведующую отделом ЦДТ пос. Дербышки.
4. Контроль за исполнением данного приказа возложить на заместителя начальника отдела образования Г.Г.Ибатуллину.

**Начальник** **Э.Р.Арсланова**

Приложение 1

**“СӘЛӘТЛЕ БУЫН”**
**шәһәр бәйгесенең район этабы**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

Яшь буында туган телдә фикерләү сәләтен һәм сөйләм культурасын үстерү, туган телгә карата мәхәббәт тәрбияләү, массакүләм мәгълүмат чаралары эшчәнлегенә җәлеп итәр өчен яхшы дикцияле, дөрес интонацияле алып баручылар, дикторлар, яшь хәбәрчеләр, талантлы каләм осталары әзерләү максатыннан үткәрелә.

**Бәйгенең максатлары һәм бурычлары**

- яшь буынның туган телдә аралашу даирәсен киңәйтү;
- рухи-әхлакый һәм милли традицияләрне яңарту;
- яшь буында толерантлык, патриотизм хисләре тәрбияләү һәм үстерү;
- яшь буында фикерләү сәләтен һәм сөйләм культурасын үстерү;
- туган телгә карата мәхәббәт тәрбияләү;
- сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үзләштерү;
- укучыларның иҗади эшчәнлеген арттыру;
- сәләтле балаларның иҗади эшләренә бәя бирү һәм сәләтләрен үстерү.

**Бәйгедә катнашу тәртибе һәм вакыты**

Бәйгедә Нигезләмә шартлары буенча билгеләнгән вакытка кадәр юллама (Кушымта 1) җибәргән, Казан шәһәре Совет районының урта гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы, татар телен яхшы белгән 1-11 сыйныф укучылары катнаша ала.

Бәйге ***2 этапта*** үтә:

Бәйгенең 1нче этабы 2023елның 10нчы мартына кадәр Совет районының урта гомуми белем бирү оешмаларында уздырыла. Мәктәпләрдә җиңүче укучыларның эшләрен**, һәр төркем һәм һәр номинация буенча 2-әр иң яхшы дип табылган эшләрне** район этабында катнашу өчен район оештыру комитетына юллама бирә. Юлламалар мәктәп директорлары имзасы һәм мөһере белән расланган булырга тиеш.

Бәйгенең район буенча финалы 2023 елның 14 нче мартында Совет районы Дәрвишләр бистәсе балалар иҗаты үзәге базасында уздырылачак.

Бәйгедә катнашу өчен түбәндәге яшь үзенчәлекләре буенча гомуми белем бирү оешмалары җиңүче дип сайлап алынган укучыларны тәкъдим итә:

- 1 нче төркем: 1-4 сыйныфлар
- 2 нче төркем: 5-8 сыйныфлар
- 3 нче төркем: 9-11 сыйныфлар

Район этабында катнашу өчен юлламаларны **2023 елның 12нче мартына кадәр** Leisan-Ant@mail.ru электрон адресына кадәр җибәрү сорала.

**Бәйге номинацияләре:**

- “Яшь диктор” (ирекле темага тапшыру алып бару, видеоязма);
- “Яшь журналист” (ирекле темага интервью алу, видеоязма);
- “Яшь шагыйрь” (яшь язучы) (үзе язган шигырен, әсәрен тәкъдим итә);
- “Нәфис сүз остасы” (видеоязмада шигырь яки проза әсәреннән өзек тәкъдим итә);
- “Тел бистәсе” (махсус номинация) (юмор, сатира чыгышын видеоязмада тәкъдим итә).

Чыгышларның вакыты – **3 минуттан артмаска тиеш.**

**Бәйгене уздыру шартлары:**

Бәйгедә катнашучыларның чыгышларын объектив бәя бирү өчен оештыру комитеты тарафыннан жюрилар билгеләнә. Конкурс жюрилары составына Казан шәһәре Совет районы Мәгариф бүлеге вәкилләре, мәдәният, сәнгать, журналистлар, язучылар чакырыла.

Оештыру комитеты Бәйге рекламасын Татарстан Республикасы мәгълүмат чараларына, интернет порталларына бирергә хокуклы.

**Жюри эше**

* Жюри һәр бәйге биремен 10 баллык система буенча бәяли;
* Жюри һәр номинациядә җиңүчеләргә 1, 2, 3 урыннар билгели.

Жюри карары үзгәртелми һәм кабат каралмый.

**Конкурсантлар чыгышын бәяләүгә таләпләр:**

- татар телендә камил аралашу;
- сөйләм культурасы;
- башкару осталыгы;
- стандарт булмаган шартларда тамашачы игътибарын җәлеп итү;
- артистлык осталыгы;
- оригинальлек;
- чыгышка туры килә торган өс киеме;
- чыгышка иҗади якын килү;
- югары дәрәҗәдәге осталык, яңалык, кызыклы идеяләр һ.б.

**Бәйге нәтиҗәләре**

- Бәйге җиңүчеләре Совет районы мәгариф бүлеге дипломнары белән бүләкләнә.

**Өстәмә мәгълүмат**

Сораулар белән 89050218741 телефон номеры аша, Ләйсән Мансуровнага мөрәҗәгать итәргә була.

Кушымта 1

**"СӘЛӘТЛЕ БУЫН"**

шәһәр бәйгесенең район этабында
катнашу өчен юллама

| № | Катнашучының исем фамилиясе, сыйныфы | Мәктәбенең татарча тулы исеме | номинация исеме һәм сылтамасы | Җитәкчесенең исем, фамилиясе, атасының исеме, электрон почтачы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

"___" __________ 2023ел.

***Искәрмә: Юллама тәкъдим ителгән үрнәк буенча гына кабул ителә.***